**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Башлыгы**

**Карары**

**13 ноябрь, 2023 ел** **№ 9**

**«Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Иске Юмья авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 24 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Юмья авылы, Үзәк урам, 87 а йорты адресындагы Иске Юмья авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 24 ноябрендә 19 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Иске Юмья авылы, Үзәк урам, 87 а йорты адресындагы Иске Юмья авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Иске Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иске Юмья авылының Яр буе урамы, Гвардия урамы, Үзәк урам, Мәктәп урамында юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, Иске Юмья авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавлары, стволлары, күчергечләре, колонкалары, мотопомпалары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Иске Юмья авылы җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;

- Иске Юмья авылында суүткәргеч системасын, су суырту манарасын, скважиналарны һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, су суырту манарасы өчен бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»

- Иске Юмья авылында традицион җирләү урыннарын карап тоту, ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү, җирләү йортын төзү, ремонтлау, чүп контейнерлары сатып алу, урнаштыру, моточапкычлар, бензопычкылар, генератор һәм инвентарь (көрәкләр, тырмалар, ломнар, баскычлар) сатып алу проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын, авыл мәдәният йортын төзү, ремонтлау, аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Иске Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;

- урам яктырту җайланмасы, урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Иске Юмья авылында һәйкәлләрне ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүлү.

5. Оштырма-Юмья авыл башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы С.В. Тимофеев

ОГРН 1021607752737
ИНН 1623001692